# Әниемә бүләгем

***1.*** Яз килде, яз! Бүген –
Әниләр бәйрәме! Әниләр бәйрәме!
Диңгездәй чайкала
Чәчәкләр бәйләме, чәчәкләр бәйләме.

Ә минем күң(е)лемдә
Җыр туа тын гына.
Җыр туа сөекле
Әнием турында.

***Кушымта (2 тапкыр):***
Әнием, әнием,
Кадерлем син минем.
Син назы, шатлыгы,
Кояшы күң(е)лемнең.

***2.*** Чагылыр ул җырда
Иң кайнар теләгем, иң кайнар теләгем,
Җылытып әнкәмнең
Тынгысыз йөрәген, тынгысыз йөрәген.

Яшә гел кояштай,
Сүрелми, сүнмичә.
Яшә гел бәхеттә,
Кайгылар күрмичә.

***Кушымта (2 тапкыр):***
Әнием, әнием,
Кадерлем син минем.
Син назы, шатлыгы,
Бәхете гом(е)ремнең.